КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1333

2021 елда мәгариф өлкәсендә, муниципаль мәгариф оешмаларын тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландыру һәм аларның территорияләрендә урам яктырткычын урнаштыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елда мәгариф өлкәсендә, муниципаль мәгариф оешмаларын тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландыру һәм аларның территорияләрендә урам яктырткычын урнаштыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 22 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1333 нче
карары белән расланды

2021 елда мәгариф өлкәсендә, муниципаль мәгариф оешмаларын тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландыру һәм аларның территорияләрендә урам яктырткычын урнаштыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2021 елда мәгариф өлкәсендә, муниципаль мәгариф оешмаларын тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландыру һәм аларның территорияләрендә урам яктырткычын урнаштыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – шул ук эзлеклелектә муниципаль берәмлекләр, башка бюджетара трансфертлар, җирле үзидарә орган) бирү һәм бүлү кагыйдәләрен билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2021 елга Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары:

муниципаль берәмлек территориясендә тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландыруны һәм муниципаль мәгариф оешмалары территориясендә урам яктырткычын урнаштыруны таләп итә торган муниципаль мәгариф оешмалары булу;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне һәм бу объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында» 2019 елның 2 августындагы 1006 номерлы карары нигезендә муниципаль мәгариф оешмасына куркынычлылык объектының беренче, икенче, өченче яки дүртенче категориясен бирү.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма

бюджет исемлегендә) 2021 елга финанслашу өчен башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә кирәкле күләмдә бюджет ассигнованиеләре булу;

бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә Министрлык белән җирле үзидарә органы арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 8 пунктында каралган документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларына туры килмәве.

8. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен җирле үзидарә органы Министрлыкка Министрлык тарафыннан билгеләнгән срокларда түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявка;

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

2021 елда тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландырылырга һәм территорияләрендә урам яктырткычы урнаштырылырга тиешле муниципаль мәгариф оешмалары исемлеге (әлеге исемлеккә муниципаль мәгариф оешмаларына объект куркынычлылыгының беренче, икенче, өченче яки дүртенче категориясен бирүне раслый торган документлар теркәлә);

2021 елга муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителгән, вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында муниципаль берәмлекнең финанслашу өчен башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган карардан (җыелма бюджет исемлегеннән) өземтә.

9. Җирле үзидарә органыннан кергән документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә карап тикшерелә. Документларны карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлык башка бюджетара трансфертлар бирү турында йә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бу турыда, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, җирле үзидарә органына хәбәр итә.

Җирле үзидарә органы тарафыннан бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән бер яки берничә документны тапшырылмаган очракта, шулай ук җирле үзидарә органы тарафыннан бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәгән очракта, Министрлык башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Җирле үзидарә органы бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

Җирле үзидарә органының яңадан бирелгән заявкаларын карап тикшерү тәртибе беренче тапкыр бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе белән охшаш.

10. Башка бюджетара трансфертлар бирү Министрлык белән җирле үзидарә органы арасында Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше һәм алардан файдалану шартлары;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе, күләме һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченең мәгънәсе;

дәүләт финанс контроле органнары һәм Министрлык тарафыннан уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре, башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау фактлары һәм әлеге Тәртип һәм килешүдә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, башка бюджетара трансфертларны алучы тарафыннан файдаланылган суммаларны кире кайтару тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары.

11. I-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме ($P_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = K \times (Z_1 + Z_2 + Z_3) \times N,$$

монда:

K – тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары һәм урам яктырткычы приборлары белән җиһазландыра торган муниципаль мәгариф оешмалары саны;

$Z_1$ – тавыш белән хәбәр итү системаларын сатып алу, аларны урнаштыру һәм эшләтеп җибәрүне көйләү өчен вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган смета чыгымнары күләме, сум;

$Z_2$ – видеокүзәтү камераларын сатып алу, аларны урнаштыру һәм эшләтеп җибәрүне көйләү өчен вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган смета чыгымнары күләме, сум;

$Z_3$ – урам яктырткычы приборларын сатып алу, аларны урнаштыру һәм

эшләтеп җибәрүне көйләү өчен вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган смета чыгымнары күләме, сум;

N – муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның 0,5 тигез дәрәҗәсе.

12. Муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү өчен муниципаль берәмлек бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме, килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәләренә ирешү кирәклегеннән чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә билгеләнә).

13. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече – муниципаль мәгариф оешмаларын тавыш белән хәбәр итү системалары, видеокүзәтү камералары белән җиһазландыруга һәм аларның территорияләрендә урам яктырткычын урнаштыруга 100 процент җәлеп итү.

14. Муниципаль берәмлекләр тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечен фактта ирешелгән күрсәткечләре белән чагыштыру аша гамәлгә ашырыла.

15. Җирле үзидарә органы башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапны һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турындагы хисапны килешүдә каралган форма, сроклар һәм тәртип нигезендә Министрлыкка тапшыра.

16. Җирле үзидарә органы тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

17. Башка бюджетара трансфертлар килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

18. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферлар бирү шартлары бозылган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

19. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферлар бирү шартлары үтәлешен тикшерүдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

20. Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

21. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчасы 2022 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

22. Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.